КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июнь г.Казань № 595

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 2 июнь, 331 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы; 2020 ел, 22 апрель, 316 нчы, 2021 ел, 12 май, 327 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен исәпкә алу буенча автоматлаштырылган мәгълүмат системасы белән үзара эшчәнлек өчен (алга таба - махсуслаштырылган программа продукты)» сүзләрен «, Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен исәпкә алу буенча автоматлаштырылган мәгълүмат системасының бер өлеше булып тора» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымтада каралган Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Реестрга исәпкә алу объектын кертү өчен яки исәпкә алу объекты турында белешмәләр составына үзгәрешләр кертү өчен мәңгелек хокукта яисә закон нигезендә дәүләт милкенә ия булган юридик зат (алга таба - Гариза бирүче) гаризаны әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә (алга таба - гариза) электрон формада

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен исәпкә алу буенча автоматлаштырылган мәгълүмат системасының бер өлеше булган махсуслаштырылган программа продукты ярдәме белән (алга таба - тиешенчә махсуслаштырылган программа продукты, исәпкә алу системасы) әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымтада каралган тәртиптә җибәрә.

Гаризада түбәндәгеләр бар:

Реестрга алар турында белешмәләр кертелә торган исәпкә алу объектлары исемлеге;

Реестрга белешмәләр кертү өчен нигез булып торучы документның күчермәсе (исәпкә алу объектлары исемлеге күчемсез мөлкәт объектларын үз эченә алган очракта).

Бер үк вакытта гариза Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә яисә озату хаты белән кәгазь чыганакта җибәрелә (гаризаны Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы аша җибәрү мөмкинлеге булмаган очракта).

Кәгазь чыганакта җибәрелгән очракта, гариза түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

юридик затның исеме кыскартмыйча китерелә;

гариза битләре номерланган, тегелгән, мөһер сугылган (булган очракта);

текст тикшерелеп язылган, гаризаның зарарланулары, чистартулары яки сызылган сүзләре һәм аларның булуы аның эчтәлеген һичшиксез аңларга мөмкинлек бирми торган, анда әйтелмәгән башка төзәтүләре юк.

Әгәр дәүләт унитар предприятиесе гариза бирүче булса, гариза белән өстәмә рәвештә вәкаләтле орган тарафыннан теркәлгән устав күчермәсе җибәрелә.

Электрон рәвештә махсуслаштырылган программа продукты ярдәмендә тапшырыла торган исәпкә алу объектлары исемлегендәге белешмәләр Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә йә кәгазь чыганакта җибәрелә торган белешмәләргә тәңгәл булырга тиеш.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кадастр (шартлы) номеры;»;

2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кадастр (шартлы) номеры;»;

3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кадастр (шартлы) номеры;»;

4 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кадастр (шартлы) номеры;»;

5 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кадастр (шартлы) номеры;»;

әлеге Тәртипкә 6 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин